


Елнын елында балаларнын җәйге ялын оештыруга хокүмәтебез һәм Мордовия районнары житәкчелеге тарафыннан зур игътибар бирелә.
Мордовия мәгариф министрлыгынын Матбугат хезмәте тарафыннан бастырылган мәгълүмат буенча, республикабыз территориясендә хәзерге вакытта 253 мәктәп яны лагере эшли. Аларда 9727 укучы ял итә.
Ведомствода учреждениеләр рес- публиканын 16 районында һәм Саранскида эшли, дип әйтәләр.       Аларнын һәркайсында балалар очен белем бирү программалары эшләнгән, алар ялны файдалы итеп үткәрергә момкинлек бирелә.
Мәктәп яны лагерьлары программа-лары балаларнын яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып тозелгән. Ул үз эченә акцияләр һәм рухи-әхлакый, патриотик тәрбия бирү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлтелгән торле кызык лы ярышларны алган. Дәүләт ярдәменә мохтаж балаларга аеруча игътибар ителә.



Мәсәлән, июньнен бер конендә генә дә Ләмберә районы татар мәктәпләрендә оештырылган ял лагерьлары тыгыз эш-чәнлек алып баралар.



Пензятка авылы китапханәсе белән авыл Мәдәният йорты хезмәткәрләре, «Салават кvпере» мәктәп яны лагерендә ял итvче балалар очен, экологик уен оештырганнар.
Шулай ук лагерьларда ял итvчеләр очен Аксен, Кривозерье Мәдәният йортлары хезмәткәрләре кvнел ачу программалары vткәргәннәр.
Рузаевка районы Татар Пешлә мәдә- ният йорты хезмәткәрләре vткән атнада мәктәп яны лагерендә ял итvчеләр очен конкурслар, викториналар, уенлы программалары дискотека белән тәмамланган.
Шул ук числода Кадошкино районы Латышовка мәктәбе «Кояш нуркайлары» дигән ял лагерендагы балалар авыл китапханәсендә «Китап коне» vткәргәннәр.
Кондезге мәктәп яны лагерьлары vз эшчәнлекләрен хәрби-патриотик, туган якны ойрәнv, лингвистик, сәнгати-эстетик, физкультура-спорт юнәлешләрендә алып баралар.
Үткәрелгән һәрбер чара балаларга рәхәтлек алып килгән – кvнелле ял иткәннәр.
Шулай ук июль-август айларында мәк- тәпләрдә ял мәйданчыклары оештыру планлаштырыла.

**Н.ХӘЛИЛ**